

скульптура «Лошадь с жеребенком».

На празднике по случаю открытия общественной территории были отмечены люди, которые внесли значительный вклад в проведение работ. Альберт Абзалов наградил Благодарственным письмом Законодательного Собрания Свердловской области за многолетний добросовестный труд и высокий профессионализм **Маргариту ПАРХЕТА**, мастера ООО "Строитель-11" (г. Красноуфимск).

Альберт Феликсович придает особое

исторической и патриотической направленности, которые теперь широко демонстрируются в школах и колледжах. На данный момент «Ирбис» объединил в себе военно-патриотические и кадетские клубы, спортивно-военный центр, казачье общество и юнармейские отряды. Альберт Феликсович вручил руководителю Центра Николаю Пчелину подарок, который поможет юным воспитанникам проходить огневую подготовку.

***Соб.инф.***

Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев, Курган өлкәсе татар конгрессы рәисе Марат Юнысов, Курган өлкәсе депутаты, "Кургансемена" акционерлык җәмгыяте генераль директоры Марат Исламов, Йолдыз авылы имамы Әхмәдулла хәзрәт Хәбибуллин һәм Милли Шураның Россия регионнарындагы әгъзалары катнаштылар.

***Бөтендөнья татар конгрессының матбугат үзәге***

**МӘДӘНИЯТ**

# Язучылар белән очрашу кичәсе


Безнең телебез – матур, бөек тел. Аның ничәмә-ничә гасырлык тарихы бар. Ә матурлыгы аның җырларында, әдипләребез иҗатында чагыла.

Күптән түгел (20 нче октябрьда) Әҗегол урта мәктәбендә язучылар белән очрашу кичәсе узды. Очрашуда катнаштылар: язучы, шагыйрь, журналист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Шәйхи Маннур, Абдулла Алиш, Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай премиясе лауреаты – Ләбиб Лерон; язучы, журналист, сатирик, Г.Тукай премиясы лауреаты – Каримов Камил Әдһәм улы; язучы-драматург, «Татар информ» редакциясе, «Интертат» электрон газетасының баш мөхәррире – Латыйпов Рәмис Нурмөхәммәт улы; Татарстан Республикасының Урал төбәгендәге даими вәкиле урынбасары - Сафиуллина Фәвия Әхтәм кызы.

Кичә барышында язучылар – һәрберсе үз иҗатларының үзенчәлекләре хакында сөйләделәр, очрашуда катнашучыларның сорауларына җавап бирделәр. Алар иҗат иткән шигырьләрне үз телләреннән ишетү бигрәк күңелле булды.







Кичәгә балалар һәм укытучылар алдан ук әзерләнделәр: җырлар, шигырьләр ятладылар, төрле уен коралларында уйнарга өйрәнделәр. Китапханәче Гөлчәчәк Рафил кызы зур китап күргәзмәсе ясады. Күргәзмәдә якташ шагыйрьләребез, язучыларыбыз китаплары, кунакларның әсәрләре урын алды.

Концерт номерларын әзерләүдә бик күп көчләрен куйдылар: Валиева Лилия Камал кызы, Мунирова Айгөл Уелдан кызы, Байрамов Руслан Марат улы. Кунакларга бүләкләрне Мансурова Айгөл Айрат кызы әзерләде.

Форсаттан файдаланып, аларга зур рәхмәтләремне белдерәм.

Язучылар белән очрашу ике өлештән торды. Кунакларны унынчы сыйныф укучылары баянда уйнап, чәк-чәк белән каршы алдылар.

Кунаклар мәктәп белән таныштылар, музейны карап чыктылар, аннары актлар залында «Бер күрешү – үзе бер гомер» дигән класстан тыш чара үткәрелде. Очрашу кичәсен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Светлана Марс кызы әзерләде һәм алып барды.

Очрашуда Ләбиб Лерон шигырьләре бик күп яңгырады: Таипова Милолика, Исламов Илназ, Савченко Анастасия, Можейкис Аделина «Татар баласы». Зарипов Айдар «Песи булсаң иде". Бариева Алиса, Мусабикова Ләйсән «Үзенә охшаган». Байрамов Гомәр «Гаҗәп хәлләр». Можейкис Ангелина "Әлли-бәлли". Гайсина Рәгидә «Яшь гомер» шигырьләрен сөйләделәр. Кичәбез барышында Ләбиб Лерон сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Ләбиб абый да үзенең берничә шигырен укып китте.

Төрле уен коралларында уйнап, Абдрафиков Алмир, Мунирова Эмилия, Байрамов Гомәр, Бариева Алиса үзләренең талантларын күрсәттеләр. Әңгәмәне «Күңелле балачак» ансамбле үзләренең чыгышлары белән бизәделәр.

Безнең телебез – матур, күркәм тел. Әгәр милләтнең теле кулланылмый башласа, ул юкка чыга. Моның өчен сугыш та, кан кою да кирәкми. Телен бетерсәң, халыкның әдәбияты да, мәдәнияте дә, гореф-гадәтләре дә бетә. Безнең, киләчәк буынның төп бурычы – телебезне саклау. Тел өчен көрәш- милләт өчен көрәш ул.

Саубуллашкан чакта каләм осталары сүзе бер булды:

«Сезнең белән очрашудан зур канәгатьләнү алдык», – диделәр алар.

Ә без исә шагыйрь язучылар белән шундый ихлас очрашуга бик тә сусаган булганбыз икән...

*Милләтемнең күңел җәүһәрләрен*
*Тутык алмас, ут, су, җил алмас.*
*Җир йөзендә таулар югалса да,*
*Татар үлмәс, татар югалмас.*

*Әҗегол урта мәктәбе укытучысы*
***АХУНОВА Светлана Марс кызы***